ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2022 № 858

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәгариф оешмаларына инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы мәгариф оешмаларында инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итү тәртибен, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтүне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (Терентьева Е.Д.) әлеге карарны Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсе сайтында һәм белем бирү оешмалары җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
05.07.2022 № 858
номерлы карарына кушымта

**Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмаларында инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итү тәртибе**

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү тәртибен раслау, шулай ук аларга тиешле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 9 ноябрендәге 1309 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 12 февралендәге "мәгариф өлкәсендә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү турында» ВК-270/07 номерлы хаты нигезендә эшләнде.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының белем бирү оешмалары җитәкчеләре законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга мәгариф оешмаларында түбәндәге шартларны тудыралар һәм тәэмин итәләр:

- объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;
- хезмәт күрсәтү урынына керү өчен объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре ярдәмендә;
- объектка керү урыны каршында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәме белән;
- күрү функциясе тотрыклы бозылган инвалидларны озата бару һәм объект хезмәткәрләре ярдәмендә объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;
- объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында инвалидка объект хезмәткәрләре ярдәмендә хәбәр итү;
- хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү, алар тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр кылу турында мәгълүмат алу өчен

инвалидларга кирәкле ярдәм күрсәтү;

-психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсендәге тиешле рекомендация яки инвалидны шәхси терһәкләндерү программасы нигезендә мәгариф оешмасы тарафыннан тьютор хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү;

- түләүсез дәреслекләр һәм уку әсбаплары, башка уку әдәбияты, шулай ук күмәк һәм шәхси кулланыштагы махсус техник чаралар бирү;

- мәгариф оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән беррәттән мәгариф өлкәсендә хезмәтләр алуга һәм объектлардан файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга башка кирәкле ярдәм күрсәтү.